КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 февраль г.Казань № 129

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлеген оештыру турында» 2025 ел, 17 июль, 524 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре һәм Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкилләре эшчәнлеген оештыру турында» 2025 ел, 17 июль, 524 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллегенең бертип уставының 3.4 пунктындагы беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Чит дәүләттә Россия Федерациясе Сәүдә вәкиллеге каршындагы Татарстан Республикасының сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиле турындагы нигезләмәнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Вәкилнең:

әзерлек юнәлешләренең эреләтелгән төркемнәреннән берсе («Икътисад һәм идарә», «Сәяси фәннәр һәм төбәк белеме», «Юриспруденция», «Тел гыйлеме һәм әдәбият белеме») буенча югары белеме яки өстәмә һөнәри программалар (әзерлек юнәлешләренең әлеге эреләтелгән төркемнәреннән берсенә туры килә торган компетенция алуга юнәлдерелгән һөнәри яңадан әзерләү программалары) буенча өстәмә һөнәри белеме булган очракта, теләсә нинди югары белеме;

әлеге пунктның икенче абзацы нигезендә әзерлек юнәлеше буенча, шул исәптән тышкы икътисадый һәм (яки) тышкы сәүдә өлкәсендә яки дәүләт граждан хезмәтендә һәм муниципаль хезмәттә кимендә өч ел эш стажы булырга тиеш;

була торган дәүләтнең чит телендә яки анда кабул ителгән эшлекле аралашу телендә ирекле сөйләшә белергә тиеш. Чит телне белү, телне белү дәрәҗәсен күрсәтеп, документаль расланырга тиеш;

082/у номерлы форма буенча чит илгә чыгучылар өчен медицина белешмә кәгазе булырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин